**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 декабрендәге 5482 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 11 августындагы 2273 номерлы карары белән расланган Техника, В.Кулагин, Тихорецк урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарларына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 августындагы 3634 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 11 августындагы 2273 номерлы карары белән расланган Техника, В.Кулагин, Тихорецк урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр әзерләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 11 августындагы 2273 номерлы карары белән расланган Техника, В.Кулагин, Тихорецк урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына, планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган

материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чykканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 декабрендәге
5482 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 11 августындагы 2273 номерлы карары белән расланган**
**Техника, В.Кулагин, Тихорецк урамнары белән чикләнгән**
**территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын, әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырып, әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендә бирергә.

2. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә:

2.1. икенче абзацта «40,6698» санын «40,685» санына алмаштырырга;

2.2. җиденче абзацта «3 нче юл» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3. 1 нче «Кварталлар территориясен план буенча үстерү характеристикасы» таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары атамасы*** | **Мәйдан, га** | | | | | **Мәйдан өлеше, %** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **М-1** | | | | | |
| | **К-1** | **К-2** | **К-3** | **К-4** | **К-5** | |
| Күпкатлы торак төзелеше | - | 3,05 | - | - | - | 7,50 |
| Мәктәпкәчә учреждениеләр | - | 0,97 | - | - | - | 2,38 |
| Күпфункцияле үсеш зоналары | 10,49 | 6,42 | 2,78 | 5,90 | - | 62,90 |
| Инженерлык инфраструктурасы объектлары | - | 0,175 | - | - | - | 0,43 |
| Транспорт инфраструктурасы объектлары | - | 0,92 | - | - | - | 2,26 |
| Спорт билгеләнешендәге объектлар | - | 0,15 | - | - | - | 0,37 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Саклап калына торган объектлар территориясе | - | - | - | - | 7,21 | 17,72 |
| Гомуми файдаланудагы территорияләр (мини сквер) | 0,58 | | | | | 1,43 |
| Урам-юл челтәре | 2,04 | | | | | 5,01 |
| Территорияләр барлыгы | 40,685 | | | | | 100 |

2.4. 2 нче «Күпкатлы торак йортларны план буенча урнаштыру зонасы өчен исәпләнгән күрсәткечләр» таблицасында:

2.4.1. «1 этап» сүзләрен «1-2 этаплар» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.2. 6 нчы юлда «820» санын «871» санына алмаштырырга;

2.4.3. 9-10 нчы юлларны түбәндәге юлларга алмаштырырга:

| **Инфраструктура объектларының сыйдырышлылыгына карата булган ихтыяҗ:** | **Күрсәткеч (1-2 этаплар)** |
|---|---|
| « «Электр энергиясен җыю станцияләре белән тәэмин ителгән машина урыннары | 8 |
| Эчкә кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм эчкә кертеп-кушып төзелгән торак булмаган билгеләнештәге биналар өчен, машина урыны | 75 |
| Ф-1 физкультура-сәламәтләндерү комплексы хезмәткәрләре һәм комплекска килүчеләр өчен | 33» |

2.4.4. таблицага искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«Искәрмә: күрсәткечләр (фатирлар мәйданы, коммерция билгеләнешендәге биналар мәйданы, якында урнашкан объектларны нигезләү) кимегән очракта, парковка урыннарына һәм башка объектларга булган ихтыяҗ, Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларыннан чыгып, проектлаштыруның алдагы стадияләрендә яңадан исәпләнә, шул ук вакытта территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү таләп ителми».

2.5. 3 нче «Күпфункцияле үсеш зонасы өчен исәпләнгән күрсәткечләр» таблицасында «2 этап» сүзләрен «3 этап» сүзләренә алмаштырырга;

2.6. 4 нче «Күпкатлы торак йортларны һәм күпфункцияле үсеш зонасын план буенча урнаштыру зонасы объектлары характеристикалары» таблицасында:

2.6.1. «1 этап» сүзләрен «1-2 этаплар» сүзләренә алмаштырырга;

2.6.2. «2 этап» сүзләрен «3 этап» сүзләренә алмаштырырга;

2.6.3. «3000» санын «4613» санына алмаштырырга;

2.6.4. таблицага искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«* Төзелешнең 3 этабы объектларының характеристикалары территорияне комплекслы үстерү механизмын гамәлгә ашырганда аныкланачак».

2.7. әлеге сүзләрне:

«К-5 кварталында гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру территориясендә гамәлдәге төзелеш, коммуналь, социаль һәм транспорт инфраструктуралары характеристикалары, параметрлары сакланды. Планлаштырыла торган төзелеш параметрларын, шул исәптән төзелеш биеклеген, санитария нормаларын, шул исәптән инсоляцияне, транспорт һәм инженерлык ягыннан тәэмин итү буенча йөкләнешне нигезләмәү, Казан шәһәре Генераль планындагы җирле әһәмияткә ия объектларның урнашу урынын билгеләү зарурлыгы территорияне планлаштыру проектында К-5 кварталы территориясен план буенча үстерү характеристикаларын билгеләү мөмкинлеген юкка чыгара. Тиешле нигезләү булган очракта, объектларның эшчәнлеген үзгәртү һәм планлаштыру территорияне планлаштыру буенча аерым документлар белән башкарылырга мөмкин. Гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең һәм реконструкцияләүнең бер яки берничә чик параметрларын үзгәртү Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш»

түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

«К-5 кварталында гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру территориясендә гамәлдәге төзелеш, коммуналь, социаль һәм транспорт инфраструктуралары характеристикалары, параметрлары сакланды. Планлаштырыла торган төзелеш параметрларын, шул исәптән төзелеш биеклеген, санитария нормаларын, шул исәптән инсоляцияне, транспорт һәм инженерлык ягыннан тәэмин итү буенча йөкләнешне нигезләмәү, Казан шәһәре Генераль планындагы җирле әһәмияткә ия объектларның урнашу урынын билгеләү зарурлыгы территорияне планлаштыру проектында К-5 кварталлары территорияләрен план буенча үстерү характеристикаларын билгеләү мөмкинлеген юкка чыгара. Тиешле нигезләү булган очракта, объектларның эшчәнлеген үзгәртү һәм планлаштыру территорияне планлаштыру буенча аерым документлар белән башкарылырга мөмкин. Гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең һәм реконструкцияләүнең бер яки берничә чик параметрларын үзгәртү Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

Торак булмаган билгеләнештәге объектларны урнаштыру зоналары территорияләрен үстерү урнаштырылучы объектлардан чыгып билгеләнә торган, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар торак территорияләрне үзләштерүгә комачауламаган очракларда мөмкин».

2.8. 5 нче «Кварталлар составында төзелеш» таблицасын һәм таблицага искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

| Квартал билгеләнеше | Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары нигезендә капиталь төзелеш объектлары | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Күпкатлы торак йортлар | Мәктәпкәчә учреждение-ләр | Инженерлык инфраструк-турасы объектлары | Транспорт инфраструк-турасы объектлары | Спорт билгелә-нешендәге объектлар |
| К-2 (1-2 этаплар) | Күпфа-тирлы йорт) | Д | К | П | Ф |

Искәрмә:

*төзелешнең 3 этабындагы капиталь төзелеш объектларының саны һәм характеристикалары территорияне комплекслы үстерү механизмын гамәлгә ашырганда аныклана.

**планлаштырыла торган объектларның эшләве һәм гражданнарның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка объектлар проектлаштыруның алдагы стадияләрендә аныклана.

Экспликация:

Күпфатирлы йорт – эчкә кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм/яки эчкә кертеп-кушып төзелгән биналар булган күпфатирлы торак йортлар;

Д – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (аерым торучы);

К – котельный;

П – эчкә кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм/яки эчкә кертеп-кушып төзелгән коммерция билгеләнешендәге биналар булган күпкатлы паркинг (аерым торучы);

Ф – физкультура-сәламәтләндерү комплексы (аерым торучы)».

2.9. 1.1 «Чик параметрлар» пунктында:

2.9.1. 1 нче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары өчен төзелешне җайга салу линияләре төзелеш проектын исәпкә алып билгеләнде һәм алар, кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм

планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымында күрсәтелде»;

2.9.2. 6 нчы «Җир кишәрлекләре өчен капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең чик параметрлары» таблицасын һәм таблицага искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Квар-тал билге-ләнеше** | **Код** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре атамасы** | **Объектлар** | **Чик параметрлар** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **Җир кишәрлеге чикләрен-нән ераклык (м)** | | | **Төзелеш проценты, %** | **Төзе-леш тыгыз-лыгы (торак фонды) (мең кв.м/ га)** | **Яшелләндерү проценты (%)** |
| | | | | П | Б | З | | | |
| К-2 | 2.6 | Күпкатлы торак төзелеше (биек биналар) | Барлык төр объектлар | Төзелешне җайга салу линияләре нигезендә | | | 90 | 31,5 | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә |
| К-2 | 2.7.1 | Автомобиль транспортын саклау | Барлык төр объектлар | Төзелешне җайга салу линияләре нигезендә | | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә | - | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә |
| К-2 | 3.1.1 | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү | Барлык төр объектлар | Төзелешне җайга салу линияләре нигезендә | | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә- | - | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә- |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | ләре нигезендә | | ләре нигезендә |
| К-2 | 3.5.1 | Мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү | Барлык төр объектлар | Төзелешне җайга салу линияләре нигезендә | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә | - | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә |
| К-2 | 4.9.2 | Транспорт чараларын кую урыны | Барлык төр объектлар | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә | - | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә |
| К-2 | 5.1.2 | Биналарда спорт белән шөгыльләнү-не тәэмин итү | Барлык төр объектлар | Төзелешне җайга салу линияләре нигезендә | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә | - | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдә-ләре нигезендә |

Искәрмә:

- күпфункцияле үсеш зоналары өчен һәм К-1, К-2, К-3, К-4, К-5 кварталларында урнашкан саклап калына торган объектлар территориясендә җир кишәрлекләре өчен капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең чик параметрлары Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә билгеләнә;

- проект карарлары буенча килештерелгән нигезләүләргә туры китереп, проект белән җир кишәрлекләре чикләреннән минималь ераклык билгеләнә, ул территорияне планлаштыру сызымнарында күрсәтелгән төзелешне җайга салу линияләре (кызыл линияләрдән ераклык) нигезендә билгеләнә, алар булмаган очракта, әлеге ераклык нульгә тигез дип кабул ителә. Күрсәтелгән җир кишәрлекләренә карата төзүче тарафыннан кадастр эшләре башкарылган

очракта, кадастр эшләрен үткәрү нәтиҗәсендә яңадан ясалган җир кишәрлекләре чикләреннән ераклык – территорияне планлаштыру сызымнарында күрсәтелгән төзелешне җайга салу линияләре (кызыл линияләрдән ераклык линияләре) нигезендә, ә алар булмаган очракта нульгә тигез дип кабул ителә. Корылмаларның җир кишәрлекләре чикләреннән минималь ераклыгын билгеләгәндә, беренче чиратта, территорияне планлаштыру сызымнарында күрсәтелгән кызыл линияләрдән ераклык линияләренә, алар булмаган очракта, нульгә тигез ераклыкка таянып эш итәргә кирәк;

- фасады белән кызыл линияләр яки төзелешне җайга салу линияләре белән билгеләнгән гомуми файдаланудагы территорияләргә караган күпфатирлы торак йортлар өчен беренче катны иҗтимагый-эшлекле функциядә куллануның минималь һәм максималь процентлары – 0% һәм 100%;

- янгын сүндерү техникасының килү юлы конструктивына таләпләрне тәэмин итү шарты белән торак йортлар өчен янгын сүндерү техникасының килү юллары шулай ук О-1 гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә проектлаштырылды»;

2.10. 7 нче «Төзелешнең 1 этабы объектлары характеристикалары» таблицасында:

2.10.1. таблица атамасында «1 этабы» сүзләрен «1, 2 этаплары» сүзләренә алмаштырырга;

2.10.2. таблица юлындагы «иҗтимагый билгеләнештәге зона объекты составында» сүзләрен «территориянең күпфункцияле үсеш зонасы объекты составында» сүзләренә алмаштырырга;

2.10.3. таблица юлындагы «3000» санын «4613» санына алмаштырырга;

2.10.4. түбәндәге юллар белән тулыландырырга:

| **Атамасы** | **Куәте** |
|---|---|
| Физкультура-сәламәтләндерү комплексы (аерым торучы) | 1 объект |

2.11. Әлеге сүзләрне:

«7 нче таблицада күрсәтелгән белем бирү оешмалары арасында К-2 кварталы төзелешенең 1 этабы өчен Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасында 173 урын каралган.»

түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

«7 нче таблицада күрсәтелгән белем бирү оешмалары арасында К-2 кварталы төзелешенең 1, 2 этаплары өчен Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасында 173 урын каралган.»

2.12. 2.3 «Транспорт инфраструктурасы характеристикалары» пунктында:

2.12.1. «Складская урамын һәм Техника урамын реконструкцияләү төзелешнең 2 этабында территорияне комплексны үстерү механизмын гамәлгә ашырганда мөмкин булачак» сүзләрен «Складская урамын һәм Техникная урамын реконструкцияләү К-2 кварталы чикләрендә каралган һәм төзелешнең 3 этабында территорияне комплекслы үстерү механизмын гамәлгә ашырганда мөмкин булачак»;

2.12.2. «1, 2, 3 юллар» сүзләрен «1, 2 юллар» сүзләренә алмаштырырга;

2.12.3. әлеге сүзләрне:

«Күпкатлы торак төзелеше зонасы чикләрендә төзелешнең 1 этабы өчен 483 машина урынына исәпләнгән паркинг урнаштыру планлаштырыла. Транспорт чараларын даими саклау өчен машина урыннары торак йортларның җир кишәрлекләре өслегендә, җир асты паркингларында, торак йортлар стилобатларындагы паркингларда урнаштырыла. Торак йортларга килүчеләр өчен автомобиль кую урыннары торак йортларның җир кишәрлекләре өслегендә, торак йорт стилобатында, шул исәптән киртәли торган корылмаларсыз стилобат чикләрендә (ачык киңлектә), Техника урамының урам-юл челтәре чикләрендә һәм юллар буйлап билгеләнде»

түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

«Автомобильләрне даими саклау өчен парковка урыннары, торак йортларга килүчеләр өчен машина урыннары һәм төзелешнең 1, 2 этапларындагы эчкә кертеп-кушып төзелгән коммерция билгеләнешендәге торак булмаган биналар өчен объект яны парковкалары күпкатлы торак төзелеше зонасы чикләрендәге җир кишәрлекләре өслегендә һәм җәяү барып җитү мөмкинлеге булган, 500 метрга кадәр ераклыкта урнашкан күпкатлы паркингта планлаштырыла. Күпкатлы паркингны файдалануга тапшырганчы, кирәкле санда парковка урыннарын төзелешнең тагын да соңрак этабына караган төзелмәгән территорияләрдәге вакытлыча автомобиль кую урыннарында урнаштыру күздә тотыла.

Проект белән эчкә кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм/яки эчкә кертеп-кушып төзелгән коммерция билгеләнешендәге биналар белән кимендә 796 машина урынына исәпләнгән күпкатлы паркинг төзү планлаштырыла.

Төзелешнең 1, 2 этаплары өчен кирәкле парковка урыннарын урнаштыру ысулы һәм урыны (ачык парковкалар (шул исәптән урамнарның кызыл линияләрендә), һәм/яки җир өсте паркинглары, һәм/яки җир асты паркинглары, һәм/яки гараж-автомобиль кую объектлары, һәм/яки стилобатлар), норматив таләпләрне үтәгән очракта, проектлаштыруның алдагы стадияләрендә үзгәрергә

мөмкин, шул ук вакытта территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү таләп ителми.

Төзелешнең 3 этабы өчен парковка урыннарын урнаштыру ысулы һәм урыны (ачык парковкалар (шул исәптән урамнарның кызыл линияләрендә), һәм/яки җир өсте паркинглары, һәм/яки җир асты паркинглары, һәм/яки гараж-автомобиль куюю объектлары, һәм/яки стилобатлар), норматив таләпләрне үтәгән очракта, проектлаштыруның алдагы стадияләрендә билгеләнә»;

2.13. 9 нчы «Коммуналь инфраструктура объектлары характеристикалары» таблицасын һәм таблицага искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Атамасы** | **Характеристиклар** | **Чаралар, тоташтыру нокталары** |
|---|---|---|
| Су белән тәэмин итү | Су куллану – 423,334 $м^3$/тәүлек.<br>Су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | Тоташтыру ноктасы – «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенә караган, Кремль яр буе урамында урнашкан Ø 1200 мм һәм Альфред Халиков урамын кисеп уза торган Ø 800 мм суүткәргеч. Проектлана торган су белән тәэмин итү челтәрләренең диаметры – Ø 315 мм га кадәр |
| Су чыгару | Хуҗалык-көнкүреш агынты сулары чыгымы – 423,334 $м^3$/тәүлек | 1 нче Трактор урамындагы Ø 2000 мм канализация коллекторы. Проектлана торган хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләренең диаметры – Ø315 мм га кадәр |
| Яңгыр сулары канализациясе | Яңгыр сулары чыгымы – 119,625 л/с | Ябык типтагы яңгыр канализациясе челтәрләре төзү, алга таба Техника урамындагы гамәлдәге челтәрләргә тоташтыру. Җитештерүчәнлеге 0,81 л/сек булган локаль чистарту корылмалары. Проектлана торган яңгыр канализациясе челтәрләренең диаметры – Ø 800 мм га кадәр |
| Электр куллану | Электр белән тәэмин итүгә гомуми ихтыяҗ – 3037,4 кВт, электр белән тәэмин итү категориясе – II | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен техник мөмкинлек бар, туклану үзәге – «Искож» подстанциясе.<br>Шулай ук проект белән КЛ-10 кВ төзү өчен технологик коридорлар каралган |

| | | |
|---|---|---|
| Газ белән тәэмин итү | Проектлана торган котельныйны газ белән тәэмин итүгә гомуми ихтыяж – 9277,4 мең. $м^3$/ел яки 2410 $м^3$/сәгать | Газ бирү Богородский газ бүлү станциясеннән гамәлгә ашырыла, проектлана торган газүткәргеч Авангард урамы һәм Тула урамы киселешендәге уртача басымлы газүткәргечкә тоташтырыла.<br>Проектлана торган газ белән тәэмин итү челтәрләренең диаметры – Ø 160 мм га кадәр |
| Җылылык белән тәэмин итү | Җылылык йөкләнеше – 8,66808 Гкал/сәг. Җылылык белән тәэмин итү котельныйдан гамәлгә ашырыла | Җылылык челтәрләре котельныйдан алып кулланучы объектларга кадәр. Территорияне планлаштыру проекты территориясендә булган капиталь төзелеш объектларын җылылык белән тәэмин итү К-2 кварталында урнашкан, куәте 10,2 МВт булган котельныйдан. Проектлана торган җылылык белән тәэмин итү челтәрләренең диаметры – Ø 300 мм га кадәр |
| Элемтә | Кабель канализациясе<br>Кимендә өч хезмәт күрсәтүче оешма | «Элемтә челтәрләре» бүлеге, оператор/эксплуатацияләүче оешманы сайлап, проектлауның алдагы стадияләрендә эшләнәчәк |

Искәрмә:

- коммуналь инфраструктура объектларының күрсәткечләре, тоташу нокталары, саны, урнашу урыны һәм тибы төзелешнең 1, 2 этаплары өчен китерелгән;

- коммуналь инфраструктура объектларының күрсәткечләре, тоташу нокталары, саны, урнашу урыны һәм тибы проектлауның алдагы стадияләрендә аныкланырга мөмкин, шул ук вакытта территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү таләп ителми;

- төзелешнең 3 этабындагы объектларны инженерлык-техник яктан тәэмин итү өчен билгеләнгән инженерлык коммуникацияләрен төзү 3 этапта башкарыла»;

2.14. 2.5 пунктта:

2.14.1. «0,6585» санын «0,58» санына алмаштырырга;

2.14.2. «1 этап» сүзләрен «1, 2 этаплар» сүзләренә алмаштырырга;

2.14.3. искәрмә белән тулыландырырга:

«Искәрмә:

Яшелләндерелгән йорт яны территорияләренең гомуми мәйданы проектлана торган торак фонды саны кимегәндә яки тиешле исәпләүләр белән нигезләгәндә киметелергә мөмкин, шул ук вакытта территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү таләп ителми».

3. «III. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә»не түбәндәге редакциядә бирергә:

«Проектны гамәлгә ашыру этаплары:

10 нчы таблица

| **Этапның номеры** | **Объектлар** | |
|---|---|---|
| | **торак һәм иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге** | **коммуналь, транспорт, социаль инфраструктуралар** |
| 1 | Эчкә кертеп-кушып төзелгән коммерция билгеләнешендәге торак булмаган биналар белән ЖК-1, ЖК-2.1 күпкатлы торак йорт | Трансформатор подстанциясен реконструкцияләү, котельный төзү, локаль чистарту корылмалары төзү.<br>Күпкатлы торак төзелеше зонасында ЖК-1 өчен яссылыктагы ачык автомобиль кую урыннары, шулай ук төзелешнең 3 этабында урнаштыру планлаштырыла торган ЖК 2.2 торак йорт территориясенең бер өлешендә вакытлыча автомобиль кую урыны булдыру.<br>Эчкә кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм/яки эчкә кертеп-кушып төзелгән коммерция билгеләнешендәге биналар белән П-1 күпкатлы паркинг.<br>Күпкатлы торак төзелеше зонасында ЖК-2.1 өчен яссылыктагы ачык автомобиль кую урыннары булдыру |
| 2 | Эчкә кертеп-кушып төзелгән коммерция билгеләнешендәге торак булмаган биналар белән ЖК-2.2 күпкатлы торак | 340 урынга исәпләнгән Д-1 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе. |

| | | |
|---|---|---|
| | йорт, Ф-1 физкультура-сәламәтләндерү комплексы | Күпкатлы торак төзелеше зонасында ЖК-2.2 өчен яссылыктагы ачык автомобиль кую урыннары булдыру |
| 3 | Эчкә кертеп-кушып төзелгән коммерция билгеләнешендәге торак булмаган биналар белән күпкатлы торак йорт | |

Искәрмәләр:

1. Төзелешнең 3 этабы территорияне комплекслы үстерү механизмы тимер юллардан санитар араны исәпкә алып башкарылганда гамәлгә кертелә.

2. Төзелешнең 3 этабын гамәлгә ашырганда, проектлана торган территория территориягә хезмәт күрсәтү өчен кирәкле объектлар белән тулысынча тәэмин ителгән булырга тиеш.


3. Ачык парковкаларны (шул исәптән урамнарның кызыл линияләрендә), һәм/яки җир өсте паркингларын, һәм/яки җир асты паркингларын, һәм/яки гараж-автомобиль кую объектларын, һәм/яки стилобатларны файдалануга тапшыруны файдалануга тапшырыла торган торак һәм коммерция билгеләнешендәге торак булмаган фондларның, шулай ук социаль инфраструктура объектларының тулысынча тәэмин ителешен исәпкә алып башкарырга. Төзелешнең соңгы этапларына караган төзелмәгән территорияләрдә (балалар бакчасы урнаштыру өчен каралган территориядән тыш) вакытлыча парковкалар урнаштыру рөхсәт ителә.

4. Проектлана торган торак һәм коммерция билгеләнешендәге торак булмаган фонд санын киметкәндә яки тиешле исәпләүләр белән нигезләгәндә, автомобиль кую урыннарындагы парковка урыннары саны да кимергә мөмкин, шул ук вакытта территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү таләп ителми.

5. Балалар бакчасын төзү, тиешле программаларга кертелү шарты белән, чиратка бәйсез рәвештә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства, границ этапов планируемого развития территории

Приложение №1 к изменениям, вносимым в проект планировки территории, ограниченной улицами Техническая, В.Кулагина, Тихорецкая, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 11.08.2023 №2273




## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

**Границы территорий, линии регулирования застройки**

- граница проекта планировки территории
- граница элемента планировочной структуры
- красная линия — устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- КЛ ТОП — устанавливаемая красная линия территорий общего пользования
- красная линия — отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- КЛ ТОП — отменяемая красная линия территорий общего пользования
- линии регулирования застройки
- граница планируемого публичного сервитута
- 5 — порядковый номер зоны размещения
- 4 — вид зоны размещения объектов капитального строительства
- 0,14 — площадь зоны размещения, га
- 3.1.1 — коды видов разрешенного использования
- н.у. — максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м)
- н.у. — максимальная этажность, этаж
- существующая застройка, подлежащая сносу с целью освобождения территории в установленном законом порядке
- существующая сохраняемая застройка

план.

**Функциональное зонирование территории**

- 1 — Границы зоны размещения многоэтажной жилой застройки (9 этажей и более этажей)
- 2 — Границы зон размещения детских дошкольных учреждений
- 3 — Границы зон размещения территорий общего пользования (минискверы, бульвары, скверы, парки)
- 4 — Границы зон объектов инженерной инфраструктуры
- 5 — Границы зон объектов транспортной инфраструктуры
- 6 — Границы зон объектов спортивного назначения

**Границы планируемых элементов планировочной структуры**

- К-1 — Квартал К-1
- О-1 — Территории общего пользования, за исключением улично-дорожной сети

**Объекты капитального строительства**

- **ЖК-1** жилой дом
- **ЖК-2.1** жилой дом
- **ЖК-2.2** жилой дом
- **Д-1** дошкольная образовательная организация на 340 мест
- **Ф-1** физкультурно-оздоровительный комплекс (отдельно стоящий)
- **П-1** многоуровневый паркинг (отдельно стоящий) со встроенными коммерческими объектами
- P — места хранения и парковирования автотранспорта
- трансформаторная подстанция, реконструируемая
- котельная проект.